ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БЕЛОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

# КАРАР

16.12.2019 ел. №15

Беловка авыл җирлеге башкарма комитетының "Беловка авыл җирлеге территориясендә адресларны үзгәртү һәм гамәлдән чыгару кагыйдәләрен раслау турында" 2015 елның 01 сентябрендәге 12 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында.

«Федераль мәгълүмат адреслы система турында «Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 26 июлендәге 227-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 27.07.2010 ел, № 210-ФЗ Федераль закон нигезендә», Аксубай муниципаль районы БЕЛОВКА авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. "Беловка авыл җирлеге территориясендә адресларны үзгәртү һәм бетерү кагыйдәләрен раслау турында" Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетының 01.09.2015 № 12 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1.5 пунктның 3 абзацында: "планлаштыру структурасы элементы (кирәк булганда), урам-юл челтәре элементы" сүзләрен "урам-юл челтәре элементы һәм (яки) планлаштыру структурасы элементының атамасы (кирәк булганда)" сүзләренә алмаштырырга.
- 1.5 пунктның 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «адресация объекты - капиталь төзелеш объекты, җир кишәрлеге яисә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән адресация объектлары исемлеге белән каралган башка объект»;

1.5 пунктындагы 10 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача коммерциягә карамаган берләшмәләрен урнаштыру территорияләре» сүзләрен «гражданнарның бакчачылык яисә яшелчәчелек белән шөгыльләнү территориясе» сүзләренә алмаштырырга;

2. Әлеге карарны Беловка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында: (http://aksubayevo.tatarstan.ru.) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында: http:pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Беловка авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе: И. Р. Мәхмүтов